**Раслыйм:** ______________
**Яр Чаллы шәһәре**
**Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү**
**идарәсе башлыгы В.Х. Харисов**

***“Татарстан дигән ватаным бар,***
***Татар дигән бөек халкым бар!”***
**шәһәркүләм бәйге нигезләмәсе**

**Бәйгене оештыручылар:** Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, 14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге, балалар –яшүсмерләр иҗтимагый оешмалар бүлеге.

**Бәйгенең максаты:**
күпкырлы сәләтле, зыялы татар балаларын үстерүгә шартлар булдыру,аларны барлау һәм таныту.

**Бурычлар:**
1. Балаларга халкыбызның үткәндәге чын тарихын, фаҗигале язмышын дөрес итеп җиткерү;
2. Телебез, динебез, гореф гадәтләребез, милли йолаларыбыз, бөек шәхесләребез турындагы белемнәрен ныгыту;
3. Милләтебез язмышына битараф булмаган, милләткә тугрылыклы хезмәт итәрлек милләтпәрварлар тәрбияләүгә шартлар тудыру.

**Бәйгедә катнашучылар:**
Бәйге шәһәребез мәктәпләренең 9-10 сыйныф укучылары арасында шәхси беренчелеккә оештырыла. Һәр мәктәптән 1 укучы катнаша ала. (Үткән елларда финалга чыккан укучылар бәйгедә катнашмый.)

**Бәйгене үткәрү тәртибе:**
Бәйге 3 турдан тора:
1. Эссе бәйгесе – декабрь
2. Интеллектуаль тур ( тестирование) - февраль
3. Финал – апрель (*Финал ярышларына беренче ике тур нәтиҗәләре буенча иң күп бал җыйган 7 конкурсант чыгачак.)*

**Бәйге юнәлешләре:**

**1.Татар халкы тарихы**
- Иван IV җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Казанны яулап алуы, Казан ханлыгының Рус дәүләтенә кушылуына 465ел.
- Татарстан Республикасы.
(Мөһим даталар,вакыйгалар, бөек шәхесләребез, дөньякүләм танытучы өлкәләр.)

**2.Татар әдәбияты**
(Бу уку елында юбилейлары билгеләнеп үтүче шагыйрьләр, язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты )
- Татар әдәбияты классигы, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов тууына 130 ел.
- Татар драматургиясенең классигы, ТАССРның атказанган артисты һәм режиссер Кәрим Гали улы Тинчурин тууына 130 ел
- Күренекле прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе Мирсәй Әмир (Әмиров Мирсаяф Мәсәлим улы) тууына 110 ел.

-Татар язучысы, шагыйрь, күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевка 70 яшь.

**3. Татар сәнгате**

- Композитор, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мансур Әхмәт улы Мозаффаров тууына 110 ел.
- Татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы, рәссам, график, скульптор һәм архитектор, Татарстанның һәм Русиянең халык рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Бакый Идрис улыУрманче тууына 120ел.
- Җырчы, ТАССРның халык, атказанган артисты Гөлсем (Өммегөлсем Нурмөхәммәт кызы) Сөләйманова тууына 110 ел.
- Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, режиссер, педагог Празат Нәкый улы Исәнбәтнең тууына 90 ел.

**4. Татар халкы тормышында дин**

- Ислам дине нигезләре,төп терминнары.
- Дини бәйрәмнәр, йолалар.
- Шәһәребез мәчетләре.

**<u>Бәйге нәтиҗәләре һәм бүләкләү:</u>**

Бәйгедә катнашучылар сертификатлар, финалитслар Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе грамоталары белән бүләкләнәчәк.

(Искәрмә: бәйгенең һәр туры буенча укучылар эчен консультацияләр үтәчәк.)

*Бәйгене оештыручы Сәйфуллина Гөлкәй Фәрит кызы*
*Белешмәләр өчен телефон 89172415064*